**ГЛАВА УСАДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Усады, ул.Советская,41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УСАД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Усад авылы,Совет ур.,41

Тел./факс: +7(84365) 73-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**29 октябрь 2019 ел** **№ 2**

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең Ильино, Тимофеевка торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары

**КАРАР БИРДЕ:**

1.Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2019 елның 10 ноябрендә 10 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Ильино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының : Ильино авылы, Үзәк урамы, 25 йорт янында .

1.2. 2019 елның 10 ноябрендә 13 сәгать 00 гә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Тимофевка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының: Тимофеевка авылы, Интернациональ урамы, 1А йорт янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Ильино торак пунктында: "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ильино Усад авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган заттан 2020 елда үзара салым кертүгә 300 (өч йөз) сум күләмендә килешәсезме?:- Ильино торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга;

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Тимофеевка торак пунктында: «2020 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлегенең

Тимофеевка торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- вак таш сатып алу һәм Тимофеевка торак пунктында посёлок эчендәге юлларны ремонтлауга;

- Тимофеевка торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен төзү, ремонтлау һәм карап тотуга;

- Тимофеевка торак пунктында балалар мәйданчыгын сатып алып урнаштыруга.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе урынбасары,
Җирлек башлыгы урынбасары Д.В.Нигметзянова